**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ФЕДОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ ТЕТЮШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422380 с.Федоровка, ул. .Школьная , 1.

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**ФЕДОРОВКА АВЫЛ ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
422380 Федоровка авылы, Школьная ур, 1.

тел. (84373) 5-70-15, факс 57-0-15;e-mail: Fedor@Tatar.ru

ОКПО 93065328, ОГРН 1061672018275, ИНН/КПП 1638005058/163801001

---

**Постановление** **Карар**

**11 .03. 2025** **№ 6**

### Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлеге Башкарма комитетының салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1743 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә Федоровка авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлеге Башкарма комитетының салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыруның кушымтада бирелә торган тәртибен расларга.

2. Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә 1 апрельгә кадәр муниципаль берәмлекнең башкарма комитетына хисап елындагы һәм хисап елына кадәрге елдагы һәр салым чыгымы буенча белешмәләр җибәрүне тәкъдим итәргә:

- ташламалардан файдаланган түләүчеләр саны турында;
- Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлеге башкарма комитеты бюджетының төшеп кала торган керемнәре суммалары турында;
- Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлеге башкарма комитеты бюджетына түләүчеләр тарафыннан салым чыгымнарын стимуллаштыручы һәр салым чыгымы буенча түләү өчен декларацияләнгән салым күләмнәре турында.

3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җитәкче Никонорова Марина Юрьевнага йөкләргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче** М.Ю. Никонорова